**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 6, с.Старое Кадеево ,423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ **ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 6, Иске Кади авылы, 423117

тел.(884396) 3-13-25 факс (884396) 3-13-25 email: Skad.Cmn@tatar.ru

№24 « 14 » август 2023 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координацион яки киңәшмә органнарын булдыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 8 ноябрендәге № 15 Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль законның 13 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законына, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Иске Кади авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 8 ноябрендәге № 15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координацион яки киңәшмә органнарын булдыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 6 нчы пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «6. Координацион яки киңәшмә органы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан төзелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (Pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Кади авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Мөктәсимов Н.В.